КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 02 февраль г.Казань № 66

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1263 нче, 2023 ел, 19 май, 615 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәгә, 1.1 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Административ реформаның икенче этабы концепциясен һәм Татарстан Республикасында Административ реформаның икенче этабы концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2009 ел, 12 март, 144 нче һәм «2010 елга кадәр Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында дәүләт хезмәтләренең сыйфатын күтәрү программасын раслау турында» 2008 ел, 15 декабрь, 888 нче карарлары белән» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин